СОВЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

02.10.2023 г.Зеленодольск № 326

Зеленодольск муниципаль районы Советының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында

Зеленодольск муниципаль районы Советының норматив хокукый актларын актуальләштерү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасының «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар чыгарды**:

1. Зеленодольск муниципаль районы Советының түбәндәге карарларының үз көчләрен югалтуын танырга:

- - 2007 елның 19 сентябрендәге «Зеленодольск муниципаль районы территориясендә урнашкан гомуми файдаланудагы су объектларын шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен куллану кагыйдәләрен раслау турында»243 номерлы;

-2016 елның 11 апрелендәге «Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм счетлары (кертемнәре) булуны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» 81 номерлы;

- 2022 елның 22 июлендәге «Зеленодольск муниципаль районы территориясендә урнашкан гомуми файдаланудагы су объектларыннан шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2007 елның 19 сентябрендәге 243 номерлы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 182 номерлы.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

**Зеленодольск муниципаль районы**
**Башлыгы ,Совет рәисе** **М.П. Афанасьев**